**СОВЕТ ДАЧНОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, РТ, Высокогорский район,
п. Дачное, ул. Центральная, 11 помещ.1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДАЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, ТР, Биектау районы,
Дачный авылы, Үзәк ур., 11, 1б.

Тел./факс+7(84365) 78-3-33, e-mail: Dach.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**07.03.2025** **№6**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 07.11.2019 елның 143 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 04.02.2025 № 02-08-01 протесты нигезендә, Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 07 ноябрендәге 143 номерлы карарына (Советның 28.04.2020 № 170, 30.11.2022 №56, 27.12.2023 №16 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 1 пунктчасындагы 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган, эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләре һәм җир кишәрлекторак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык китә;»

2. Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча әлеге карарны халыкка җиткерергә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Дачный авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А. М. Дәүләтшин